ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 21 декабрендә
кабул ителде

1 статья

“Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 4^4 пункт өстәргә:

“4^4) “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында” 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законда каралган стратегик планлаштыру өлкәсендәге вәкаләтләргә;”;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6) муниципаль берәмлек икътисады һәм аның социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләрне җыюны оештыру һәм әлеге белешмәләрне Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыру;”;

2) 22 статьяның 8 өлешендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4) муниципаль берәмлекне социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау;”;

3) 24 статьяның 5 өлешендәге беренче абзацында “3 өлешендә” сүзләрен “3, 3^1 өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга;

4) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында
җирле үзидарә турында”
Татарстан Республикасы
Законына кушымта

Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләүне үткәрү, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актларга экспертиза ясау мәҗбүри булган муниципаль районнар һәм шәһәр округлары исемлеге

1) Азнакай муниципаль районы;
2) Әлмәт муниципаль районы;
3) Апас муниципаль районы;
4) Арча муниципаль районы;
5) Балтач муниципаль районы;
6) Бөгелмә муниципаль районы;
7) Буа муниципаль районы;
8) Югары Ослан муниципаль районы;
9) Биектау муниципаль районы;
10) Алабуга муниципаль районы;
11) Зәй муниципаль районы;
12) Зеленодольск муниципаль районы;
13) Кукмара муниципаль районы;
14) Лаеш муниципаль районы;
15) Лениногорск муниципаль районы;
16) Менделеевск муниципаль районы;
17) Минзәлә муниципаль районы;
18) Түбән Кама муниципаль районы;
19) Нурлат муниципаль районы;
20) Яңа Чишмә муниципаль районы;
21) Питрәч муниципаль районы;
22) Саба муниципаль районы;
23) Тукай муниципаль районы;
24) Теләче муниципаль районы;
25) Чистай муниципаль районы;

26) Ютазы муниципаль районы;
27) Чаллы шәһәре.”.

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пункты 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 23 декабрь
№ 99-ТРЗ